| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2013 Казан ш. № 5-21/э

# Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, кулланучыларга җибәрелә торган җылылык йөртү матдәсенә тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар буенча хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә әлеге карар кушымтасына туры китереп тарифлар билгеләргә

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 1 октябреннән 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2013 елның 1 октябреннән түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җибәрелә торган җылылык йөртү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 2011 елның 26 декабрендәге 5-55/э номерлы карарына 2 нче кушымтаның 1 пунктын;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Кулланучыларга, башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга «Таттеплосбыт» ААҖ җибәрә торган җылылык йөртү матдәсенә тарифлар билгеләү турында» 2011 елның 26 декабрендәге 5-58/э номерлы карарына 2 нче кушымтаның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасын, 2 пунктындагы 2.2 пунктчасын һәм 3-4 пунктларын;

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җибәрелә торган җылылык йөртү матдәсенә

тарифлар билгеләү турында» 2011 елның 16 декабрендәге 5-47/э номерлы карарына 2 нче кушымтаның 2 пунктын.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
26.09.2013 № 5-21/э
карарына кушымта

# Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар башка җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга, кулланучыларга җибәрелә торган җылылык йөртү матдәсенә тарифлар

(НДС исәпкә алмыйча)

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Тариф төре | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|
| | | | су | пар |
| 1 | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсе җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагына (чыганакларына) хуҗа булган җылылык белән тәэмин итүче оешмадан бирелгән җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә тариф | | | |
| 1.1 | «ТГК-16» ААҖ | | | |
| 1.1.1 | Чыганак – «ТГК-16» ААҖ филиалы – Казан ҖЭҮ-3 | Бер ставкалы, сум/куб.м | 19,41 | 46,91 |
| 1.1.2 | Чыганак – «ТГК-16» ААҖ филиалы – Түбән Кама ҖЭҮ (ПТК-1) | Бер ставкалы, сум/куб.м | 18,82 | 49,68 |
| 1.2 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 23,89 | 31,48 |
| 1.3 | «Генерирующая компания» ААҖ | | | |
| 1.3.1 | Чыганак - «Генерирующая компания» ААҖ филиалы - Казан ҖЭҮ-1 | Бер ставкалы, сум/куб.м | 36,73 | 63,08 |
| 1.3.2 | Чыганак – «Генерирующая компания» ААҖ филиалы – Казан ҖЭҮ-1, «Горки», «Азино» район котельныйлары | Бер ставкалы, сум/куб.м | 25,47 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.3.3 | Чыганак - «Генерирующая компания» ААҖ филиалы - Казан ҖЭҮ-2 | Бер ставкалы, сум/куб.м | 32,71 | 97,21 |
| 1.3.4 | Чыганак – «Генерирующая компания» ААҖ филиалы – Казан ҖЭҮ-2, «Савиново» район котельные | Бер ставкалы, сум/куб.м | 35,44 | - |
| 1.3.5 | Чыганак - «Генерирующая компания» ААҖ филиалы - Чаллы ҖЭҮ | Бер ставкалы, сум/куб.м | 20,57 | 65,53 |
| 1.3.6 | Чыганак - «Генерирующая компания» ААҖ филиалы - Зәй ГРЭС | Бер ставкалы, сум/куб.м | 18,01 | 18,76 |
| 1.3.7 | Чыганак - «Генерирующая компания» ААҖ филиалы - Алабуга ҖЭҮ | Бер ставкалы, сум/куб.м | 141,08 | - |
| 2 | Кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә тариф | | | |
| 2.1 | «Генерирующая компания» ААҖ | | | |
| 2.1.1 | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 27,98 | 77,37 |
| 2.1.2 | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 20,78 | 64,11 |
| 2.1.3 | «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 141,08 | – |
| 2.2 | «Таттеплосбыт» ҖЧҖ | | | |
| 2.2.1 | «Зәй шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 18,92 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.2.2 | Түбән Кама шәһәре, Түбән Кама муниципаль районының Афанас авыл җирлеге һәм Красный Ключ авыл җирлеге | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 22,52 | - |
| 2.2.3 | Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/куб.м | 31,50 | 90,11 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча
дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту
һәм теркәү бүлеге